ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31 03 2021 г. № 80

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2018 елның 15 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2015 елның 1 декабрендәге 480 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2018 елның 15 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.9. пунктның 2 пунктчасында «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасында «әлеге Регламентка» сүзләрен «Кагыйдәләргә һәм Тәртипкә» сүзләренә алмаштырырга;

3.1.2. пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

«Мөрәҗәгать итүчене һәм аның гаиләсен социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алу мәсьәләсен карау өчен кирәкле документлар исемлеге» Регламентына 3 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

«Мөрәҗәгать итүче гаиләсен социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә кую турында күрсәтмә» 4 нче кушымтасын һәм «Мөрәҗәгать итүче гаиләсен социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә куюдан баш тарту турында күрсәтмә» 5 нче кушымтасын Регламентка 3 һәм 4 нче кушымталар дип санарга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмасында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Р. Салаватов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881